Кузнечиха авыл җирлеге Советы
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

КАРАР

20.07.2022 № 45

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кузнечиха авыл җирлеге Советының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында ТР Спас муниципаль районы Кузнечиха авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Әҗмәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Кузнечиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2015 елның 08 маендагы 91-1 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар, цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш кылуга алдагы өч елда һәм алыш-биреш кылына торган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. «Әҗмәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Кузнечиха авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2012 елның 10 декабрендәге 48-2 номерлы карары белән расланган түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше), санлы финанс активлары, санлы валютаны сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчалар, муниципаль вазыйфа биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артып киткән очракта, һәм алыш-биреш кылуга алдагы өч елда алынган акча алу чыганаклары турында белешмәләр.».

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Кузнечиха авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Ибраһимов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КУЗНЕЧИХИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ КУЗНЕЧИХИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ